

Ләмберә авылы халкынын бер бик тә матур гадәтләре яшәп килә: яшәгән урыннарын матур һәм унайлы ясау. Мин сокланып бу турыда еш язып киләм: авыллары урамнарын, ой тирәләрен, бакчаларын чистарталар, яшелләндерәләр, бизәп торалар. Сонгы елларда ял урыннары булдыралар. Мәсәлән, Лямбирь авылынын Сельхозтехника микрорайонында балалар мәйданчыгы тозеп бетерәләр инде.

Мәйданчык урыны билгеләнгән, кирәксезләре сvтелгән, туфрагы тигезләнгән һәм бу урында спорт мәйданчыгы, тирбәлеш-качели һәм эскәмияләрдән торган ял итv мәй-данчыгы, балалар почмагы урнаштырыла. Жирле хакимиятнен һәм авылдашларнын ярдәменә ометләнәп, сvтелгән мәйданчык реконструкцияләнә һәм яна технология буенча урнаштырыла. Ә авыл яшvсмерләре яна мәйданчык турында хыялланып кына калмый; алар олкән иптәшләренә теләп ярдәм итәләр, бер-берсеннән чиратлап корәк алалар һәм ком тавын тигезлиләр. Балаларга тырыш хезмәтләре һәм омтылышлары очен тундырма сатып алганнар. ВКонтакте сайтында Рамиль Рифкать улы Макаев барысына да ярдәмнәре очен рәхмәтләрен белдерә: «...Бvген безгә 3 тонна вак таш һәм 5 тонна ком бvлеп бирделәр. Спорт мәйданчыгын тозеклэндерv очен, муниципаль хакимиятләр ярдәменнән башка, Мордовия Госсобраниесе депутаты, «Спецтранс-МАЗ» жәмгыятчелегенен генераль директоры Валерий Александрович Корнишин белән Александр Валерьевич Корнишинга, кvрсәткән ярдәмнәре очен, зур рәхмәт әйтәсебез килә».
Бу эшнен чын энтузиасты Рифкать улы Рамиль Макаев. Ләмберәдә туып vскән 20 яшьлек Рамиль Макаевны республикабызда максатчан спортчы буларак та беләләр. Ул балачактан ук жинел атлетика белән шогыльләнә, кvп тапкырлар Россиянен торле турнирларында Мордовия намусын яклый. Берничә ел элек (2021нче елны) Рамильне урта һонәри белем бирv оешмалары студентлары арасында региональ конкурста «Ел спортчысы» дип таныганнар. Быел егет жинел атлетлар арасында Мордовия чемпионы һәм ГТО нормативларын vтәv буенча ин яхшысы булды. Ә һонәрне ул әнисе vрнәгендә сайлаган: әнисе шәфкать туташы булып эшли. Рамиль дә Саранск медицина коллиятен тәмамлау турында диплом алды. Югары уку йортына профильле белгечлеккә укырга

кереп, белем алуын дәвам итәргә планлаштыра. Әмма Рамиль спорт белән мавыгуга тугры кала.
- Хәзер шәһәр ишегалларында һәм кайбер авылларда урам тренажерлары белән заманча спорт мәйданчыклары жиһазландырыла. ФОК янындагы район vзәгендә дә шундыйларны урнаштырдык. Ә менә минем туган «Сельхозтехника» микрорайонымда физкультура белән шогыльләнv очен бернинди жайланмалар да булмады. Һәм кvпфатирлы йортлардан килгән балаларга уйнарга урын юк иде диярлек, - дип сойли егет эшне белеп.
Шуна кvрә Рамиль, дусты Тимур Ежов белән бергә, дvрт ел элек ишегалдында гомуми файдалану очен vзләре бруслар урнаштырганнар. Ләкин бу гына житми. Шуна энтузиастлар микрорайонда кvп функцияле спорт зонасы тозергә карар итәләр.
- Әйтик, челтәр-сетка волейбольная жәеп, ишегалды командалары арасында турнирлар уздырырга була, - дип уртаклаша Рамиль Макаев. - 15 июньдә без мораль һәм физик яктан искергән карусельләр һәм баланслау - селкенv жиһазларын реконструкцияләдек һәм спорт зонасы янында тирбәлешләр, комлык һәм эскәмияләр урнаштырырга телибез. Ачык һавада ял итv очен шундый почмак барлыкка киләчәк.
Рамиль Макаев эшне барлык нечкәлекләрен исәпкә алып эш итә. Ул кайбер  спорт жиһазларын әтисе ярдәме белән дә този.
- Туфракны тигезләv, снарядларны монтажлау һәм ныгыту – асылда ике атналык эш иде. Ләкин тагын цемент, каркас очен торбалар, алар очен чылбырлар һәм беркетvләр кирәк, дип саный язма героебыз. - Беләм, хәзер торак пунктларны тозекләндерvгә юнәлдерелгән торле дәvләт программалары бар. Бары тик гаризаларны рәсмиләштерv, конкурс сайлап алу һәм башка тиз булмаган процедуралар. Тозелеш материаллары очен дә зур сумма таләп ителми.
Әмма берникадәр сумма кирәк. Шулай, 22 июльдә халык жыелышы vткән. Тозv материалларын алу очен акча жыялар. Торле жирдә яшәгән «Сельхозтехника» кешеләре булышыр дип уйлыйбыз.
Ә калганнарын без vзебез эшләя-чәкбез. Спорт, ял итv мәйданчыгын жи-һазландырырга ярдәм итvче меценатлар табылыр дип уйлыйм.
Сvз унаеннан, Ләмберәлеләр балалары һәм оныкларынын буш вакытларында сәламәтлек очен файдалы эш белән мәшгуль булсыннар очен матди ярдәм кvрсәткәннәр. Кыскасы, Ләмберәдә vз кочләре белән йорт алды спорт һәм ял мәйданчыгы тозеп балаларга унай шартлар тудыралар.

*Фото Рамиль Макаев ВКонтакте битеннэн*
**Наилә НАСЫРОВА**